6 Бердәмлек № 26 (1153), 23 июнь 2012 ел

гаебен аңлар да хатасыннан кайтыр һәм тәүбә кылыр.

Өченче юл - бер мәртәбә талак раҗигый кылу. Әгәр казый яки ике тарафның якыннары ике араны төзәтә алмасалар, бу вакытта ир үзенең хатынын бер мәртәбә раҗигый талак кыла. Шул вакытта, ихтимал, һәр ике тарафка: «Инде бер талак булды, янә ике мәртәбә талак булса, арабыз бөтенләй аерыла, кушылып торырга юл калмый, кечкенә балалар ятим кала, аларны кемнәр карар, кемнәр кулына калырлар, моннан соң нинди рәвештә мәгыйшәт насыйп булыр, кемнәр белән дөнья көтәргә туры килер? Хәерле тереклек насыйп булырмы яки бу көннәрдән дә яманрак хәлләргә очрарбызмы?» дигән уйлар төшәр дә, башларны кызгану һәм гаилә хөрмәтен саклау сәбәпле әүвәлге дошманлыкларны гафу итешерләр һәм чын күңелләреннән килешерләр; элек кылган җәбер, җәфалары өчен үкенешерләр һәм бер-берсенә тугрылыклы гаилә булып китәрләр. Мондый хәлләрнең дә булганлыгы һәрвакыт ишетелеп тора.

Дүртенче юл - икенче мәртәбә талак кылу. Ягъни, әгәр әүвәлге талактан бернинди файда чыкмаса, икенче мәртәбә талак кылу. Ихтимал ки, әүвәлге талакта булмаган әсәрләр бу икенче талакта булыр да, моннан соң янә бер талак соңында яңадан кушылуга шәригать рөхсәт бирмәячәген фикерләп, эшнең начар булачагын аңларлар да, үкенерләр һәм килешерләр.

Бишенче юл - өченче талак кылу. Икенче талактан да бернинди нәтиҗә күренмәсә, араларындагы суыклык нык булганлыгы һәм төзәлү ихтималы беткәнлеге мәгълүм булыр да, шуның өчен өченче талак кылыр. Моннан соң бу ир белән хатынның бергә тора алу ихтималы калмас. Хатын инде бу иргә бөтенләй чит кеше булыр, хәтта башка чит ирләр белән никах мөмкин булганда да, бу ир белән бу хатын яңа никах белән дә бергә яши алмаслар, хатын икенче бер иргә дөрес никах белән никах ителеп, аерылмый торып бу әүвәлге иренә янәдән бара алмас.

Талак хакында ислам шәригате тарафыннан куелган кагыйдәләр, әдәпләр шулкадәр тырышлык соңында да килешә алмау, бу ир белән хатын ирле-хатынлы булып торган мөддәтләрендә араларында өлфәт вә мәрхәмәт урнашуга һәм Аллаһы Тәгаләнең әмер вә фәрманнарын җиренә җиткерә алмауга дәлилдер. Шуның өчен боларның ирле-хатынлы булуларында мәгънә калмый. Шуңа күрә боларның бер-берсенә хәрәм булулары артык күрелә.

Бездә кайбер хатын-кызлар, әгәр ирләре юаш, сабыр булса, ирләренә урынсызга ачулары килсә дә, әйдә мине аер, синең белән торыр хәлем юк, мин синең белән торганчы, теләнчегә барсам да риза, дип тавыш күтәрергә генә торалар. Шуңа күрә хатыннар җиңелрәк фикерләүче һәм күбесенчә тиз кызучан булганлыклары өчен шәригать талак эшен сабыр һәм чыдам табигатьле ирләргә тапшырган. Моннан максат аз гына сәбәпләр, кечкенә генә ялгышлыклар белән гаилә эшләре бозылып китмәсен, һәрвакыт булып үтә торган үпкә, ачулар сәбәпле гаилә эшләренә бәрәр төрле хәл килмәсен өчендер. Ләкин безнең ирләрдә ислам шәригате тарафыннан ышанып тапшырылган бу нәрсәне явыз ният белән куллану бик күп. Хатыннары итагать белән хезмәт итеп, бөтен мәшәкатьләрен уртаклашып, бөтен хезмәтләрен башкарып торган хәлдә бик күп ирләр үзләре яратмау яки башка бер үзләренчә яхшыракка, матурракка күзләре төшү сәбәпле хатыннарын аерырга карар бирәләр. Бу эш шәригатьнең чарасызлык вакытында гына хупланырга тиешле талак хөкеменә көфран нигъмәт кылу була.

Талак Аллаһы Тәгаләгә сөелмәгән бер нәрсә булса да, мәхәббәте булмаган, аны үзенә иптәш санамаган, аның өстеннән йөрүдән оялмаган кешенең үз хатынын җәберләп, каһәрләп тотуы бигрәк тә сөелмәгән эштер.

**Нурислам хәзрәт ИБРАҺИМ.**
*(“Иман” газетасыннан)*

***4-5 ИЮЛЬ – БӘРАӘТ КИЧӘСЕ***

# Бәраәт балкышы

Матур кичәләрнең берсе – мөбарәк Бәраәт кичәседер. «Бәраәт» сүзе – гөнаһ, гаеп, хаталар, бурыч вә җәзалардан котылу димәктер.

Бәраәт вә Кадер кичәләре – җомга һәм бәйрәм көннәре кебек мөбарәк көн вә кичәләр. Мөселманнарның Аллаһыга юнәлеп, төрле гыйбадәтләр белән мәшгуль булган, хәерле вә матур эшләр башкару, дога, тәүбә вә истигъфар белән гөнаһларының багышлануына ният иткән, ялварган бәрәкәтле вә муллык заманыдыр.

Бәраәт кичәсе бөек нигъмәт вә форсаттыр, бәлегез! Чөнки танылган, мөбарәк кичәдер. Шәгъбанның унбишенче кичәседер. Кадер кичәсе бик бөек булып та, кайсы кичәдә булганы билгеле түгелдер.

*«Бу кичәдә күп итеп гыйбадәт кылыгыз. Югыйсә, кыямәт көнендә үкенечкә калырсыз!»* (хәдис-шәриф)

*«Бәраәт кичәсендә күп итеп дога кылу, начар гамәлләрдән, имансыз булудан Аллаһы Тәгаләгә сыену, җәһәннәм утыннан котылу бәраәте, бәрәкәт, рәхмәт, гафу ителү вә сәламәтлек теләүләр кирәктер»* (хәдис-шәриф).

Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) иң күбе Шәгъбан аенда, аеруча Бәраәт кичәсе якынлашкан көннәрдә нәфел уразасын тоткан вә моның сәбәбен сораганнарга:



бүлдермәгән. Әгәр берәрсенең сүзе чамадан чыкса, ул аны я кире каккан, я торып киткән.

Аллаһы Рәсүле галәйһиссәләм күршеләрен хөрмәт һәм кунакларын ихтирам белән кабул иткән. Аның Аллаһы өчен хезмәт итмәгән яки яхшы гамәл кылмаган бер генә минуты да булмаган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм киләчәккә өмет белән караган, төшенкелеккә бирелүне яратмаган. Ул ике эшнең берсен башларга кирәк булганда, аларның иң файдалысын сайлаган. Ул бәлагә төшкәннәргә ярдәм итәргә һәм мәзлүмнәрне коткарырга яраткан.

Аллаһы Илчесе галәйһиссәләм үзенең тарафдарларын бик яраткан, алар белән еш киңәшләшкән һәм алар турында кайгырткан. Әгәр тарафдарларыннан берәрсе авырып китсә, ул аларның хәлен белергә бара торган булган. Әгәр берәрсе югалып торса, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм аны эзләгән. Берәрсе вафат булса, аның хакына дога кылган. Ул һәрвакыт башкаларның гафу үтенүен кабул иткән, аның өчен кечле дә, көчсез дә үз хокукларында тигез булган. Сүз остасы буларак, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм күп төрле гыйбрәтле хикәяләр һәм тарихлар сөйли торган булган. Ул һәрвакыт дөресен генә сөйләгән.

Аллаһы Рәсүле галәйһиссәләмнең тәрбиялеге һәм әдәплелегенә килгәндә, ул тарафдарларына бик мәрхәмәтле, хөрмәтле мөнәсәбәттә булган, кысан җирдә һәрвакыт башкаларга күбрәк урын калдырган. Берәрсен күрсә, ул аны һәрвакыт беренче булып сәламләгән.

Аллаһы Илчесе галәйһиссәләм бик тыйнак булган. Кешеләр җыелган җиргә яки җыелышка килгәч, ул урын бар җиргә утырган һәм моның белән барысының да бертигез хокуклы икәнлеген ассызыклаган. Әңгәмәдәше белән утырганда беркайчан да аннан алда торып басмаган. Ашыккан вакытта һәрвакыт гафу үтенгән.

Хөрмәтле мөселманнар! Пәйгамбәребез галәйһиссәләм беркайчан да ярлыларга фәкыйрьлекләре өчен җирәнеп карамаган, байлар алдында түбәнчелек күрсәтмәгән. Ул һәрвакыт иминлекне югары куйган. Ашаганда, эчкәндә уң кулын файдаланган, чөнки аңа Аллаһы шулай кушкан. Ул хуш исләрне яраткан: суган, сарымсак кебек начар ис таратучы нәрсәләрне сөймәгән. Аллаһы Илчесе галәйһиссәләм үзенең тарафдарларыннан киеме белән дә, җыелышларда утырган урыны белән дә аерылып тормаган. Берәрсе килсә: «Әй сезнең кайсыгыз Мөхәммәд соң?» – дип сорый торган булган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм киемнәрдән ашык сөягенә кадәр җитүче озын җилән киеп йөрергә яраткан. Кием-салымда да, ризыкта да бернинди артыклыкны кабул итмәгән. Башына чалма һәм башлык кия торган булган, ә уң кулының чәнчә бармагында көмеш балдагы булган.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтте: *«Ий кешеләр, тәхкыйк, сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, Аллаһыга карышуыгыз аңар авырдыр, сезнең иманга килүегез өчен ул бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьледер»* (“Тәүбә” сүрәсе, 128нче аять).

«Күңелебездә Пәйгамбәребезгә мәхәббәт бармы?» – дигән сорау бирәсе килә.

Ни өчен без бәхетсез соң? Бездән Раббыбыз канәгатьме? Тормышыбыз кая бара? Без кешеләр белән нинди мөнәсәбәттә? Без аларга ярдәм итәбезме, аларны аңлыйбызмы? Яисә без үзебез турында гына уйлыйбызмы?

Сорауларга җавап табыйк та, тормышыбызны үзгәртик, җәмәгать!

**Нияз САБИРОВ,**
**Ш. Мәрҗани исемендәге көллият директоры урынбасары,**
**Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы.**
*(“Татар мөселман календаре”ннан)*




**- Мәҗлесләрдә ничек кенә тырышсам да, кеше тизлегенә өлгерә алмыйм. Кешеләр тәһлил әйтеп бетерә, мин исә яртысына гына җиткән булам. Бер апа белән сөйләшкән идек. Ул: «Лә иләһә» дип кенә әйтәләр бит», - диде. Ә мин: «Лә иләһә илләллаһ», - дип әйтәм. Кайсыбызныкы дөрес була икән?**

- Тәһлил әйтү – Аллаһыга тәсбих, зикер кылу. Тәһлил әйтүне ни рәвешле һәм нинди күләмдә буласын Рәсүлебез ачыктан-ачык әйтмәгән.

Чыннан да, күп кенә кеше: «Өлгереп булмады», – дип әйтә. Чынлыкта, кешеләр тәһлилне өлгерә алган кадәр, ихластан әйтергә тиеш. Ә инде йөгерешкә чыккан кебек, кеше белән куышып утыру – дин гамәле түгел. Зикер, тәсбих кешенең йөрәгеннән чыгарга тиеш. Тәсбих тарту – ул төймәләрне күчереп утыру түгел, ә чын күңелдән Аллаһыга зикер әйтү.

Әгәр башкалар артыннан өлгермибез икән, кайда туктасак та, шунда туктыйк һәм кулларыбызны күтәреп, Аллаһыга дога кылыйк. Ә инде билгеле бер санга, мәсәлән, йөз яки меңгә тутыру дигән нәрсә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә юк. Элеккеге галимнәр дә нииндер төгәл сан тутыру белән шөгыльләнмәгәннәр, ә ихластан укырга тырышканнар. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, сан артыннан куу түгел, ә ихласлык кирәк.

Тәһлилдә: «Лә иләһә илләллаһ», – дип әйтсәң дә дөрес, әмма иң хәерлесе: «Лә иләһә илләллаһ Мөхәммәдү рәсүлуллаһу», – дип әйтү. Чөнки Пәйгамбәребез безгә шулай өйрәтте. Ә без һаман да, үзебезгә җиңеләйтергә теләп, һәрнәрсәне кыскартырга тырышабыз.

**“Дин-Ислам” мәчете имам-хатыйбы**
**Инсаф ИБӘТУЛЛИН.**
*(“Дин вә йола” газетасыннан)*